ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

25.02.2022 с. Верхний Услон 182

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау турында Нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 3 февралендәге 191 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законны, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, "Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында" 2014 елның 07 мартындагы 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, "Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының факттагы йогынтысын бәяләүне һәм экспертизасын уздыру тәртибе турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" 2021 елның 30 сентябрендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру, муниципаль идарәнең нәтиҗәлелеген һәм аларны җайга сала торган карарларны әзерләү һәм кабул итү өлешендә муниципаль идарәнең нәтиҗәлелеген арттыру һәм камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма

комитетының 2017 елның 3 февралендәге «Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза ясау турындагы нигезләмәне раслау турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 3 февралендәге 191 номерлы карарына 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә чыгарырга:

«Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен артык бурычлар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә этәрә торган нигезләмәләрне, шулай ук эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектларының һәм җирле бюджетларның нигезләнмәгән чыгымнары барлыкка килүгә ярдәм итә торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында уздырыла».

2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-икътисадый үсеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе И. И. Шакиров